Сабира Сталберг

# Филип һәм томан



**Сабира Сталберг**

# Филип һәм томан

**Фазилә Насретдин тәрҗемәсе**
**Мария Виитасало рәсемнәре**

2 җиңел тел

aybagar

Хельсинки 2022

**Җиңел тел дәрәҗәләре**
Дәрәҗә 1: Иң җиңел
**Дәрәҗә 2: Җиңелрәк**
Дәрәҗә 3: Җиңел

Tatar, Cyrillic script
1. басма/edition

Швед телендә / Original:
Sabira Ståhlberg: *Filip och dimman*
Тәрҗемә: Фазилә Насретдин
Translation: Fazile Nasretdin
Рәсемнәр / Illustrations: Maria Viitasalo

Эш төркеме: Альбина Самархан,
Камәр Яфай Ногманов,
Дәрия Самалетдин, Адилә Самалетдин

Мөхәррир: Лилия Дәүләт

© Сабира Сталберг, 2022
© Фазилә Насретдин, тәрҗемә, 2022
© Мария Виитасало, рәсемнәр, 2022

Айбагар ▸ aybagar.eu
Хельсинки / Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-83-6 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-84-3 (е-китап, PDF)

# Бүлем 1

Бүген Филипнең туган көне.
Ул аны өйдә гаиләсе һәм
туганнары белән бәйрәм итә.
Барча туган-кардәшләре
диярлек кунакка килә.

Филип торт пешергән.
Тортны әнисе пешерергә теләгән дә,
Филип ярдәм кирәкми дип белгерткән.
Торт үзенчәлекле.
Филип аны үзе уйлап чыгарган.
Ул үзенең торты белән горурлана.

Торт Җир шарына охшатып ясалган.
Төсләре зәңгәр һәм яшел.
Бизәү өчен Филип караҗиләк ширбәте
һәм бөтнек яфраклары кулланган.
Күпертелгән каймактан
тауларга ак түбәләр ясаган.
Котыплардагы боз да ак.
Тортның чүлләре сары.
Алар өчен Филип бер банан изгән.

Филип Җир шары турында кайгыртуын
кунакларына күрсәтергә тели.

Ул климат үзгәрешләре турында
гел уйланып йөри.
Төньяк һәм көньяк котыпларында
бозның эреп баруы аны иң күп борчый.

Филип хайваннарның күп төрләре
югала дип тә кайгыра.
Ул хәзерге вакытта Җир турында
күп укый. Нигә климат үзгәрә һәм
үзе ни эшли алыр иде дип тә беләсе килә.

Үзгәрешләрне туктатыр өчен
кешеләр ни булса эшли алалармы?
Әлегә Филип белми.
Төрле чаралар турында уйлана.

София кузины һәм Бибинур апа
килеп җиткәннәр инде.
Алар башка шәһәрдә яшиләр.

София белән тагын очрашканга
Филип шат.
Аның белән сөйләшү күңелле.
Ул да табигать белән кызыксына.
Күрешкәндә Филип белән София
хайваннар, диңгез һәм күп башка
күңелле нәрсәләр турында
сәгатьләрчә сөйләшәләр.

Башкалар тыңлап торырга туялар да,
качып китәләр.

Бибинур апа һарвакыттагыча
Филипнең ачуын китерә.
Пуделен да китергән һәм
шул нәни Бикбае өчен
бөтен вакыт тынычсызланып тора.
Эт нәрсәдән генә хасталана ала дип
Бибинур апа шикләнеп тора.
Аеруча Филипнең торты
Бикбайның ашказанын
бозарга мөмкин дип әйтә.

Аяз абый тагын да соңга калган.
Филип абыен ярата.
Ул ападан бөтенләй аерылып тора.
Аяз тыныч һәм акыллы.
Аның Филип белән сөйләшергә
һаман вакыты бар.

Аяз күп сәяхәт итә һәм
күргән-кичергәннәрен сөйли.
Алар икәү мөһим эшләр
турында сөйләшәләр,
мәсәлән, кит ничек тиз йөзә ала.
Филипнең нәрсәләр ятратканын
Аяз бик яхшы белә.

Хәзер инде кардәшләр өстәл артында
утыралар да каһвә һәм чәй эчәләр.

Әби әни белән апа арасында утыра.
Ул апа белән сөйләшә.
Филип әбигә карый да,
бераз күңеле төшә.
Бабайның үлгәненә тиздән бер ел була.
Филип бабайны сагына.

Әби ялгыз калды.
Ул исе китмәгәнгә салышса да,
үзен ялгыз хис итә.
Аны барысы да белә.
Кайвакыт әби көнгә берничә
тапкыр шалтырата
һәм шул ук сүзен
кабат-кабат сөйли.
Ул сөйләшергә генә тели дип әни әйтә.

Әби илтифатсыз була башлаган.
Әүвәл бик ямьле киенә иде.
Матур алтын-көмеш бизәнү
әйберләре бар иде.
Барысы да аның зәвыгына
сокланалар иде.
Соңгы айларда алтын-көмешләрен
дә такмый.

Әбинең күлмәге еш бөрешкән
һәм анда-монда таплар бар.

Бүген тагын әби киемен
үтүкләргә онытткан.
Ул турыда беркем дә
бернәрсә әйтми.
Әйтергә килешми дип
уйлыйлар кардәшләр.

Әби үзе бераз картайдым
гына дип уйлый.
‒ Филип, аңлыйсың бит, ‒
аның шундый әйтә торган гадәте бар.
‒ Кешегә картайгач онытырга ярый.
Кайчан булса әйберләр дә югала.
Башым бер дә эшләми.

Филип алай уйламый.
Әбәй әби кебек ук карт,
әкин әбәй үткен.
Беркайчан да бернәрсәне дә онытмый,
әйберләрне дә югалтмый.
Әбәй һәрвакыттагыча җитез.
Ишек кыңгыравы чыңлый.
Филип ишекне барып ача.
Аяз киң итеп елмаеп
болдырда басып тора.

– Туган көнең котлы булсын, Филип! –
дип кычкырып җибәрә.
Филипне кысып кочаклый.

– Менә син теләгән китап, –
Аяз әйтә.
– Бу китап кешенең һәм хайваннарның
психологиясе турында.

Филип аларның үз-үзләрен тотышлары
турында укырга ярата.
Нигә кешеләр һәм хайваннар
үзләрен төрлечә тоталар,
аны Филип белергә тели.

Филип абыйсына рәхмәт укый да,
китапны карый башлый.

– Бүген кичен укырсың, – абый әйтә.
– Ә хәзер туган-тумачаларның
хәлләрен белешәбез.

Алар башкалар янына баралар.
Аяз абый әби янында туктый да:
– Әнкәй, блузаңны үтүкләргә
онытканмсың! – дип әйтә.

# Бүлем 2

Киләсе шимбә көнне әни
Филипкә, әбигә бармассыңмы, дип әйтә.
Гадәттә әни үзе бара, ләкин
кич белән аларга кунаклар килә.
Әнигә кичке ашны әзерләргә кирәк.

– Яңа гына икмәк салдым,
әстерхан чикләвеге белән, – әни әйтә.
– Әбинең иң яраткан икмәге бу.
Алып барырсың бит?

Әби Филипләргә якын яши.
Җәяү барырга ун минут үтә.
Әби күптән түгел яңа фатирга күчте.
Элекерактарак тора иде,
әмма хәзер әнигә
якынрак яшәргә тели.

Бибинур апа башка шәһәрдә яши
һәм Аяз абый еш чит илләрдә йөри.
Филипнең әнисе гел өйдә
һәм ул әбигә булыша ала.

Филип җылы икмәкне алып
әби янына китә.

– Һәй, Филип, – әби әйтә.
– Яхшы иттең, килдең.
Яраткан икмәгемне дә
алып килгәнсең!
Утыр, сыр белән ипиләр ашыйк.
Чәй куям.
Бәлки ширбәт телисеңдер?
– Рәхмәт, чәй, – Филип әйтә.
– Бөтнек һәм бал белән.
– Хәзер була, – әби җавап бирә.
– Мәктәптә эшләр ничек бара?
Дустыңның хәле ничек?
Исеме ничек иде? Камил? Шамил?

– Хәлил, – Филип җавап бирә.
– Ул һаман очкычлар ясап торамы? –
әби сорый.
– Инженер булырга тели ахрысы?
– Юк, Хәлил химияны ярата, – Филип әйтә.
– Ул очкычларны яратмый.
Химик булырга уйлый.
– Ой, алайса ялгышам, – әби әйтә дә,
аптырап калганга охшый.

– Минем сыйныфымдагы Мими
очучы булырга тели, – Филип әйтә.
– Ул очкычлар белән кызыксына.
Ләкин ул үзе аларны төземи.

Очарга гына тели.
‒ Кызык, ‒ әби мыгырдый.
‒ Һәркемнең үз шөгыле булырга тиеш,
шулай бит?
Әби ашханәгә кереп югала.
‒ Нигә кемдер көзгенең
урынын алыштырган, ‒
сөйләнгән тавышы ишетелә.
‒ Һаман шунда бәреләм.
Мич тә урынында түгел.
Төнен бәдрәфне тапмыйм.

‒ Әби, син бит күчтең, ‒ Филип әйтә.
‒ Күнәргә вакыт кирәк.
‒ Филип, мине ‒ карт әбиеңне
кереп баккан өчен мин бик шат.
Әле аңлатчы, син ниләр
эшләп йөрисең? ‒ әби сорый.

Филип аңлата башлый.
Ул әби белән сөйләшергә ярата.
Әби һәрнәрсә белән кызыксына.
Бик әйбәт тыңлый да,
беркайчан ахмак сораулар бирми.
Ләкин әле ул чыннан да
тыңламый дип Филип сизә.
Эшләрне дә буташтыра.
Әбинең кулында тәпсе.

Тәпседә чокырлар,
табаклар һәм бал кашыклары.
– Бал!
Син бал теләгән идең бит.
Аны оныттым, – әби әйтә.

Кинәт әби абынып китә.
Филип тиз-тиз тора да, тәпсене
чак кына тотып алырга өлгерә.
– Кан басымы, – әби әйтә.
– Табиб биргән дару яхшы түгел.
Миңа даруханәдән
яңа дару барып алырга кирәк.
Ләкин минем эшем бик күп,
анда барырга вакытым юк.

Филип тәпсене өстәлгә куя да:
– Әби, чәйнек кайда?
Ә кайдан янган ис килә? –
дип сорый.
Ашханәгә керә.
Әби мичнең дөрес күзен
кабызмаган икәнен күрә.
Ул су кайнатыр өчен бер
юмаган казанны кайнарга куйган.

– Казанның төбе янган, – әбисе
Филипнең аркасы артында әйтә.

– Аны ташларга кирәк, – дия.

Аннары бераз әкрен тора да:
– Филип акыллым, әниеңә берни дә
әйтмәссең бит?
Ул һәрнәрсә өчен
минем белән талаша.
Казан мөһим түгел.
Вакытың булганда
миңа шундый ук казан
сатып алырсыңмы?
Менә сиңа акча.

– Әлбәттә, – Филип әйтә.
– Бу безнең сер булсын, –
әби әйтә дә күз кыса.

# Бүлем 3

Берничә көннән соң Филип казан
сатып ала. Аны әбигә илтә.
Әби шатлана да,
Филипне кысып кочаклый.
– Рәхмәт, акыллым!
Ничек миңа казан
китерергә уеңа килде? – сорый.
– Син моны миннән сораган идең бит, –
Филип исе китеп әйтә.

Ни булганны Филип ачык итеп аңламый.
Әби иске казан төбен
яндырганын хәтерләмиме?
Филип әбине күзәтә.
Әбигә нидер булган.
Ул үзгәргән.
Өс-башын бакмаган.
Чәче күптән юылмаган.
Өендә сасы ис.

Әби өен җыештырмый ахрысы.
Ашханәнең асты өскә килгән.
Савыт-саба юу урынында һәм өстәлдә
тәлинкәләр, чәнечкеләр,
пычаклар өем-өем тора.

– Әби, сиңа булышсам,
ярармы? – Филип сорый.
– Мин чүпләрне чыгарып ташлыйм?
Савыт-сабаларны да юалам.
– Кирәк түгел, – әби әйтә.
– Кичә чүпләрне ташлаган идем.

Филип аңа карап ала.
Әби ялгыша.
Ул чүпләрне бер атна буе ташламаган.
– Мин чүпләрне алып чыгам, –
Филип нык кына әйтә.
– Сау бул, күрешербез.
Яхшы тор.

Филипнең күңеле төшә.
Сасы исле капчыкны ыргыта да,
авыр адымнар белән өйгә таба китә.
Әби ни өчен шундый сәер икән?
Нигә өен җыештырмый?

Бабай әле исән вакытта
өйләре һаман ап-ару
һәм тәртипле иде.
Бабай хаста булганда,
әби барысын да кайгырта иде.
Кичке аштан соң чүпләрне
һәрвакыт ташлый иде.

Әни белән сөйләшергә кирәк,
Филип уйлый.
Ул, әлбәттә, ни булганны беләдер.

Ләкин өйгә кайткач, әни белән
сөйләшергә һич тә мөмкинлек тапмый.

Аяз абый диванда утыра.
Телефоны өстәлдә.
Аны күзәтеп тора.
Аяз кырыс күренә.
Әнинең күзләре кызыл.

– Филип! Анда икәнсең, – әни әйтә.
– Синең турыда сөйләшәбез.
Ничек син шундый әдәпсез була аласың?
Әбинең пенсиясе бик аз,
син аны белмисеңме?

– Филип акчаларны урлаган дип һич
тә уйламыйм, – Аяз әйтә.
– Нәрсә турында сөйләшәсез? –
Филип сорый.
– Әби Бибинур апага шалтыраткан.
Әбинең өеннән акча югалган.
Акчаларны син урлагансың дип
апа уйлый, – әни әйтә.
– Бибинур апа бая гына шалтыратты.

Әби акчаларны дөрес санамагандыр
дип уйлым, – Аяз өсти.
– Әби һәрзаман тугрылыклы, – әни әйтә.
– Мин белгән кешеләрдән
иң тугрылыклысы.
Ул сәбәпсез беркайчан
да беркемне дә гаепләмәс.
– Әби гаепләми бит,
апа Филипне гаепли, – Аяз искә төшерә.

– Мин әле аңлый алмыйм, – Филип әйтә.
– Әби, син киткәч, янчыгында
акчалар юк дип сизгән, – Аяз әйтә.
– Атна ахырында син генә
анда кереп чыктың, – әни әйтә.
– Әмма… – Филип башлый,
ләкин әнисе аның сүзен бүлә:

– Филип, акчаларны шунда
ук кире кайтар!
Ничек алай эшли алдың?
Әбиеңнән ничек урлый алдың?
Сиңа кесә акчасы бирәбез бит.
Җитмиме?

– Мин Филипкә ышанам, – Аяз әйтә.
– Әлбәттә, бу эшкә башка җавап бардыр.
Шулай бит, Филип? – Аяз өсти.

Филип тирән сулап ала.
Әни ничек апаның сүзенә ышана ала?
Нигә ул мин әбидән
урладым дип уйлый?
Бу беркайчан уема да килмәс иде.
Нигә Бибинур апа мине гаепли?

Апа һаман шундый инде.
Ул Филипне яратмый һәм
һаман ялгыш нәтиҗәләр ясый.

– Әби миңа акча бирде, –
Филип әйтә башлый.
– Дөрес түгел, –
әни Филипнең сүзен бүлә.
– Әби сиңа акча бирмәгән дип әйтә.
Әби беркайчан да ялган сөйләми.
– Филипне тыңла, – Аяз әйтә.

Филип бераз вакыт уйлап тора.
Серне сөйләргә микән?

Ул бит әбигә берни дә
сөйләмәскә сүз бирде.
Серне бирәсе килми.
Филип үзен хыянәтче дип тоя.
Алай булса да эш ничек икәнен
әйтергә яхшырактыр.

– Әби казан төбен яндырды.
Яңа казан алыр өчен
миңа акча бирде.
Казанны озак та түгел
әбигә илттем.
Ләкин ул аны сораганын
хәтерләмәде, – Филип аңлата.

– Филип, син ялган сөйләсәң,
беттең, – әни куркыта.
– Әле куертасың, – Аяз абый әйтә.
– Кайвакыт Филип нидер башыннан
уйлап чыгарырга мөмкин дә,
акча яки башка җитди эш
турында ялган сөйләмәс ул.

Аяз диваннан тора да, әйтә:
– Әбигә барабыз да,
барысы да анда яхшымы
дип тикшерәбез.
Мин чыннан да әби турында
борчыла башладым.

Әни, Филип һәм Аяз әби янына киләләр.
Әни ишек кыңгыравына баса.
Беркем дә килеп ачмый.
Ачкычын чыгарып, әни
ишекне ачып җибәрә.

Әби өйдә түгел. Филип туп-туры
ашханәгә барып керә.
– Тегендә мин сатып
алган казан һәм
менә хисабы, – күрсәтә.
– Менә калган акчалар.

Казан әле дә алган көендә,
төрелгән килеш.

– Белдем бит, –
Аяз абый әйтә.
– Филип гаепсез.
Әмма каян
мондый сасы ис килә?

– Әби өен җыештырмый
инде, – Филип әйтә.



# Бүлем 4

Аяз абый әбинең өен әйләнеп чыга.
– Иске аш калдыклары, – дип мыгырдана.
– Өстәл өстендә ипи валчыклары
һәм таплар. Юыну бүлмәсе пычрак.
Әби һәрхәлдә ике атна
буе тузаннарны суыртмаган.
Керләр юылмаган.
Гаҗәп, әби өен ничек карый?
ТВ кабынган, димәк,
ул еракка китә алмаган.

Әни урындыкка утыра.
– Мин ышаналмыйм, – дип әйтә.
– Гафу ит, Филип, синнән шикләндем.
Апаң син дип мине инандырды.
Бибинурга түгел, мин үземә
ышанырга тиеш идем.
Әби хәтерен югалткан икән.

– Шулай әкрен-әкрен була, – Аяз әйтә.
– Әби хәтерен әз-әзләп югалткан.
Андый хәл, гомумән,
ни булса булгач кына сизелә.
Филип, син кибеткә йөгереп барып,
сорап карыйсыңмы?

Әбине күргәннәрме?
Ул арада без монда өйне җыештырабыз.
Филип чыгарга тора.
Әнисенең күзләре яшь белән
тулганны күреп ала.

Аяз абый әнине юатырга тырыша:
– Картлыктан, – Аяз әйтә.
– Күп кеше мондый
авырлыкларга дучар була.
Без моңа ни дә эшли алмыйбыз.
– Нигә безнең әниебез? – әни үкси.
– Нигә ул әүвәлге кебек көчле
һәм шат тора алмый?

Филип ишекне ябып чыга.
Аның куллары калтырый.
Әнисе дә әбисе өчен борчыла.
Әби кайда була ала?
Тышка чыкканда нигә ТВ ны
кабызып калдырган?
Соңгы вакытларда ул бик сәер.
Иске заман турында гына сөйли.
Филипнең гел тыңлыйсы да килми.
Шул ук хикәяне ул
әздән унбиш кат ишеткән.
Бәлки дә әбинең тормышы
кызык түгелдер?

Аны бернәрсә дә
артык кызыксындырмый инде.
Дуслары да күп калмады,
беркем кереп тә бакмый.
Әби гәзитә укый, ТВ карый,
ләкин тирә-ягынданиләр булганга
исе дә китми.

Аңа кирәге юк.
Әби үткәннәрдә яши һәм
иске эшләр турында уйлана.
Кайвакыт бабай әле
исән кебек сөйләшә.
Филип башын чайкый.

Мин әбинең сәер булуы турында
уйларга тиеш түгел.
Әбине ничек табарга,
миңа шул турыда уйларга кирәк.
Филип кибеткә керә.
Кибет әби яшәгән йорт янында ук.

Филип киштәләр арасында йөренә,
ләкин анда әби күренми.
Кассага бара да, кассачы ападан
әбине күргәнме дип сорый.
Апа әбине дә, Филипне дә белә.
– Әйе, – кассачы әйтә.

– Ул биредә иде.
Прәннек сатып алды.
Егерме минут әүвәл моннан чыкты.

– Кайсы якка киткәнен
күрдеңме? – Филип сорый.
– Уйлыйм, шәһәргә таба китте, –
кассачы әйтә.
– Минемчә бераз сәер.
Ул беркайчан да шәһәргә
җәяү китми иде.

– Ул гадәттә автобус белән
бара, – Филип әйтә.
– Еракка йөрергә аяклары чыдамый.

Филип ашыгып-ашыгып
әбинең өенә кайта.
Абый белән әни иске гәзитәләр
һәм шешәләр җыеп торалар.
– Әби шәһәргә таба җәяү киткән, –
йөгерүдән тыны кысылган Филип әйтә.
Әнинең йөзе агара.
– Тиз-тиз. Безгә әбине караңгы
төшкәнчегә кадәр табарга
кирәк, – әни әйтә.

# Бүлем 5

Аяз абый полициягә шалтырата.
– Хәтере һаман эшләми, –
телефон аша әйтә.
– Тышкы кыяфәте? – полиция сораша.
– Пәлтәсе яшел һәм итекләре кара, –
Аяз аңлата.
– Хәтерләү авыруы булган кеше турында
сүз бара? – полиция сорый.
– Әйе, хәтере ягыннан авырый торган
кеше дип әйтеп була.
Беләм, сезгә аларны еш кына
эзләргә туры килә.
Ләкин бу минем әнием, һәм дә
бу мәсьәлә минем өчен беренче.

Филипнең эченә гүя салкын
боз кисәге кереп утыра.
Әби авырый.
Шуңа күрә ул бик сәер.
Хәтерен югалту гына түгел,
бу хасталык.

Филип калтырана.
Үзен бик начар хис итә.
Кеше ничек кинәт эштән чыга ала?

Нәрсә аны үзгәртә?
Нигә?
Һәм дә мин ни эшли алам?
Әни әтигә шалтырата,
әмма ул җыелышта, җавап бирми.
‒ Моны безгә үзебезгә хәл итәргә кирәк, ‒
дип әни көрсенеп куя.

‒ Зур урам буйлап үзәккә таба барабыз.
Әби шул юл белән барадыр.
Мин урамның уң ягыннан барам,
син сул ягыннан, ‒ әнигә Аяз әйтә.
‒ Филип, син кем белән барасың, сайла.
‒ Мин ялгыз барам, ‒ Филип әйтә.
Аңа уйларга кирәк.
Аны Аязга әйтергә теләми.

Урамга чыгалар да, Филип
туп-туры алга китә.
Аның башында төрле уйлар
әйләнеп йөри. Ачык уйларга тырыша.
Әбигә ни булса булганмы икән?
Аны ничек табарга?
Әбинең уйлау ысулын
күз алдына китерә.
Әби кая барыр иде икән?
Тукта, автобус белән киткән булса?
Автобус.

Әлбәттә!

Филип тирә-ягына карый.
Абый белән әни, икесе дә, туктаганнар да,
әби турында сорашалар.

Урамда танышлары белән фикерләшәләр.
Караңгы төшә дә, фәнәрләр кабына.
Урам өстенә томан төшә.
Томан куера бара.

Филип көчкә йөз метр алга күрә.
Әле әбине табарга ашыгыч.
Томан эчендә юлдан
адашырга мөмкин.
Филип автобус килгәнне күрә.
Тиз булырга кирәк.
Әнигә һәм Аязга берни
әйтергә өлгерми.

Автобуска керә дә,
өч тукталыштан соң төшә.

Автобустан төшкәч,
бер йортка барып керә.



# Бүлем 6

Электән әби бу йортта яши иде.
Филип өченче катка йөгереп менә.
Дөрес уйлаган.
Бер ишекнең алдында әби басып тора.
Аптыраганга охшый.
Чәче төрле якка таралган.
Пәлтәсе бер җилкәсендә салынып тора.
Ул аны салырга тырышкан, күрәсең.

Әби иске өенә кайткан.
Филипне күргәч, йөзе яктырып китте.
– Сәлам, – әби шатланып әйтә.
– Инде яхшы, килдең.
Ачкыч белән проблема бар.
Ул биккә керми.
Син ачалсаң,
чәй һәм чигелдәк бирәм.
Кибеткә кергән идем.

Филип көлә.
Рәхәтләнеп китә.
Ләкин бер үк вакытта йөрәген
салкын кул йомарлагандай тоя.
– Әби, син монда тормыйсың инде, –
Филип әйтә.

– Бу синең иске өең.
Әле кая торганыңны мин хәзер күрсәтәм.

– Юк-барны сөйлисең, – әби мыгырдый.
– Мин монда торам.
Ник мин башка җирдә торам ди?
– Син бит күчтең, хәтерлисеңме?
Син әле безгә якын торасың.
Филип әбигә борчылып карый.
Күченгәнен хәтерли микән
яки оныткан микән?

Әби маңгаен тота.
– Әйе шул, бик дөрес әйтәсең, –
кычкырып җибәрә.
– Әле хәтерлим.
Әмма ник мин монда?
Ничек шундый ахмак булырга инде?
Мин дөньяның иң ахмак дәү әниседер.
Ничек мондый тиле булырга?
Әниеңә бернәрсә дә
әйтмәссең бит, Филип?

Әни белән абый аны эзлиләр бит.
Аны әбисенә аңлата.
– Алайса берни дә эшләп булмый, –
әби әйтә.
– Хәтерем элеккеге кебек эшләми.

Безгә моны белеп яшәргә кирәк.

Филип әнисенә шалтырата,
ләкин аның телефоны мәшгуль.
Ул әти белән сөйләшәдер.

Филип Аяз абыйга шалтырата.
Абый шунда ук Филипкә ярдәм
кирәкме, дип сорый.

‒ Яхшы, ‒ Филип әйтә.
‒ Әби йөри ала бит.
Автобус белән кайтабыз.
Филип әби белән тукталышка таба бара.
Әби берни дә әйтми.
Автобуста да әкрен генә утыра.
‒ Әби, хәтерләмисең дип кайгырма, ‒
Филип әйтә.
‒ Эшләрне оныту нормаль.
Үзең дә картайдым дип әйтәсең бит.

‒ Әмма бу һич тә дөрес түгел, ‒ әби әйтә.
‒ Кайда торганымны беләм бит.
Бу кадәр оятка беркайчан да
калганым юк иде.
Сиңа, әниеңә, әтиеңә һәм Аяз абыеңа
миннән мәшәкать кенә.
Әби бераз уйлап тора да:

– Хәтерем артык эшкә ярамый.
Аны җайларга кирәк яисә яңасын алырга.
Син беләсеңме, кайда яңа
хәтерләр саталар?

Филип көлә.
Әбинең юморында бернинди зыян юк.
– Бу без чыга торган урын түгелме, –
әби сорый.
– Юк, – Филип әйтә.
– Киләсе тукталыш.

– Яхшы күрмим дә инде, – әби дәвам итә.
– Тиздән күрүемне дә, ишетүемне дә
югалтырмын инде.
Уйлап карачы,
карталар йортына эләксәм?
Мин аны бөтенләй теләмим.
Миңа калса, картлар йорты –
иң начар урын. Ә кузгала да алмасам,
ни булыр? – әби төелеп әйтә.

Филип әбине юатырга тырыша,
ләкин ул тыңламый кебек.
Автобустан төшкәндә әни белән
Аяз абый аларны көтеп торалар.
– Сез кайда идегез, – әни борчылып
кычкырып җибәрә.

– Элекке фатирыңа барырга инде.
Андый ахмак фикер уеңа ничек килде?
– Автобус белән бардым, – әби аңлата.
– Әбигә каныкма, – Аяз әйтә.
– Әле өйгә кайтабыз.

Филип әбисе белән тын гына бара.
Әнисе бертуктамый сөйли.
Аның аптырап калганын Филип күрә.
Әнисенең борчылганын аңлый да,
әби өчен аның файдасы юк.

Филип әнисенә бик нык ачулана.
Шул ук вакытта әнисе өчен борчыла да,
Филип әнисен беркайчан да мондый
ярсулы күргәне юк.

Әби үз-үзенә елмая.
Ниндидер җыр көйләп бара.
Әнинең әйткәннәренә исе дә китми.
Сөйләвен ишетми дә кебек.

# Бүлем 7

Икенче көнне Бибинур апа шалтырата.
– Сез әбине табибка алып барырга тиеш, – дип телефоннан кычкыра.
– Уйлап карагызчы, аңа нәрсәдер
була күрсә?
Ничек сез мондый
илтифатсыз була аласыз?
– Тынычлан, – әти әйтә.
– Без киләсе атнада барырга вакыт
алдык инде.

Әни Бибинур апа белән сөйләшергә
теләми, аннан борчыла гына.
Бибинур апа бик күп киңәшләр
биреп тора, ә үзе
әби белән очрашырга да теләми.

– Эшем бик күп.
Вакытым юк.
Ярдәм итәр өчен берни дә эшләми.
Әбине Филипнең әнисе генә багарга тиеш.

Әле әни көн саен әби янына бара.
Өй җыештырылган.
Сасы ис тә килми инде.

Әби әле дә табибка барырга теләми.
– Нигә мин табибка барырга тиеш, –
дип сорый ул.
– Мин бит сау-сәламәт.
Хәтерем генә бераз иске.

– Үзеңне тикшертсәң, яхшырак бит, –
Аяз абый әйтә.
– Аннары нинди дарулар кирәк, белербез.
– Миңа бернинди дә
дарулар кирәкми, – әби әйтә.
– Минем хәлем бик яхшы.
Гомерем буе үземне үзем карадым,
нигә әле карый алмас идем?
Миңа ничек яшәргә кирәк,
аны мин үзем иң яхшы беләм.

Әбинең борчылганын Филип сизә.
Тагын эчендә боз кисәге оешканны тоя.
Әүвәл әби тынычсыз түгел иде.
Шат һәм тыйнак иде,
табибка да теләп бара иде.
– Барысы да яхшы булсын иде,
тикшертергә кирәк, – дип әйтә иде.

Табибка барырга бер сәгать калгач, өчәү –
Филип, әни һәм әти әбигә баралар.
Әби хәзер генә торган.

Юынмаган, киенмәгән дә.
Аларның килүеннән тынычсызлана.

Өйдә ары-бире әйберләрен
эзләнеп йөренә.
Янчыгы югалган,
кулъяулыкларын да тапмый.

– Табиб? Бүген? –
дип кычкырып җибәрә.
– Пәнҗешәмбе көнне түгелме иде?
Ник кичә берни дә әйтмәдегез?
Ник килер алдыннан
шалтыратмадыгыз?
Башымны һаман буташтырасыз.



# Бүлем 8

Табиб әбигә яңа дарулар кирәк дип әйтә.
Әни даруларны сатып ала һәм
әби аларны кабамы дип
күзәтергә тырыша.
Әмма әни еш өйдә юк,
курсларда һәм семинарларда була.
Ул чакларда әти, абый һәм Филип
әбигә баралар.

Бибинур апа һәркөн шалтырата да,
үгет-нәсыйхәт бирә.
Ләкин үзе күренми дә,
Софияга да әби янына ялгыз
килергә рөхсәт бирми.

Берничә айдан соң Аяз абый
Филипләрнең ишек
кыңгыравын шалтырата.
Үзе бик җитди күренә.
Ул әбинең хәлен тикшертер
өчен аны табибка алып барган.

– Әбине картлар йортына
урнаштырырга кирәк, –
Аяз абый әйтә.

– Озакламый әби өендә ялгыз тора алмас
инде дип, табиб миңа аңлатты.
– Юк, – ди әни.
– Юк, берничек тә мөмкин түгел.
Әбинең үзенең фикере буенча,
барысы да яхшы.
Өйдә торса, аны яхшы карарга
гына кирәк.
Ул эшне без кайгыртырга тиешбез.

– Әби картлар йортына
барырга теләми, –
Филип өсти.
– Анда озын коридорлар һәм
ялгыз кешеләр генә бар дип әйтә.
– Сез аны үз өегездә
карарга телисезме? – Аяз сорый.

– Андый мөмкинлегебез юк, –
ди әти.
– Мин әбине карый алам, –
Филип сүзне бүлә.
– Мәктәптән соң аш
пешерә алам һәм
өйне җыештыра алам.

– Юк, алай булмый, –
Аяз җавап бирә.

– Олы кеше өчен дә бу
бик авыр эш.
Синнән белемлерәк һәм
көчлерәк кеше кирәк.
Әгәр әби егылса, аягын
сындырса, нишләрсең?
Яки кинәт ачуланса да, сиңа сукса?

– Әби миңа беркайчан да сукмый, –
Филип каты әйтә.
– Суга ала, теләмәсә дә, – Аяз әйтә.
– Әбинең баш мие элеккечә эшләми.
Ул искәрмәстән ачулана һәм
нәрсә дә булса эшли ала.

– Хосусый картлар йорты
яхшырак, – ди әти.
– Анда аны әйбәт карыйлар.
Анда төрле шөгыльләр бар
һәм ризык тәмле.
– Моның өчен акчагыз бармы? –
дип Аяз сорый.
– Минем фатир өчен бурычым бар,
аны мин түләргә тиеш.

– Нигә социаль хезмәт ярдәм итми, –
әни мыгырдый.
– Әби өчен җәмгыять нәрсә эшли?

Ул гомере буе эш эшләгән һәм
елларча салым түләгән.
Ни өчен аны өендә карап булмый?

– Карау өчен әбинең
акчасы кулланыла, – Аяз әйтә.
– Әмма ул кыйммәткә төшә.
Озак яшәрме, беркем белми.
Ике яки өч ел яисә бәлки дә ун ел?

– Син әби турында ул үлгән инде
кебек сөйлисең, – әни әйтә.
– Юк, – ди Аяз.
– Уйла бераз.
Әбигә ярдәм кирәк.
Уңайсыз хәл булганнан әүвәл
бу мәсьәләне хәл итәргә тиешбез.

– Бу дөрес түгел, – ди әни.
– Әби үзен карый ала.
Аңа тагын да күчәргә кирәк, дип
мин әбигә әйтә алмам дип уйлым.
Элек тә яратмады.
Әби торган җирендә кала.

Филип һәм әти башларын кагалар.
Алар әни кебек уйлыйлар.
Әби үз өендә яшәргә тиеш.

Беркемне белмәгән ят җирдә түгел.
Бигрәк тә аны беркем
танымаган җирдә.

– Без якын торабыз бит, –
Филип әйтә.
– Берни дә аңламыйсыз, –
Аяз ачуланып әйтә.
– Бибинур апа сезгә караганда
тагын да яманрак.
Вакытында ярдәм бирмәсәк,
әби өчен тагын да авыррак була.
Яхшы каралмаса,
ул үләргә мөмкин.

Аяз чыга һәм чыкканда
ишекне бәреп яба.

# Бүлем 9

Айлар үтә, Аяз абый
һич шалтыратмый.
Ул әбигә анда беркем
булмаганда гына килеп китә.

Әби гел Аяз турында сөйләп тора.
Аяз бик акыллы.
Аяз бик ягымлы.
Ул барысыннан да зиһенле
һәм барысыннан да яхшы.
Әни белән Бибинур апа
Аяз абыйга якын да килмиләр.

‒ Бүген биергә барасыңмы? ‒ әби сорый.
‒ Ни дисең? ‒ әни әйтә.
‒ Минем елларча биергә барганым юк.
‒ Әйе, әмма... ‒ әби әйтә.
‒ Алай булса, үзеңә ир ничек табарсың?
‒ Мин ирдә инде, балам да бар, ‒
әни әйтә.
‒ Филип минем улым, хәтерлисеңме?
‒ Филип, ул кем? ‒ әби сорый.

Көннән-көн әбинең уйлары
сәеррәк була бара.

Кайвакыт ул Филипнең кем
икәнен хәтерли,
әмма еш ул кемнең
баласы дип тә сорый.

Әби авыртуларым бар дип тә зарлана.
Йоклый алмыйм дип әйтә
һәм аштан да кала.
Аш пешерергә әбинең көче җитми инде.
Ул күбесенчә диванда ятып ТВ карый.

Филип нәрсәдер сораганда,
әби еш җавап та бирми.
Кухняда кемдер тавышласа,
бик каты тынычсызлана.
Кайвакыт Филипкә кычкыра.
Әмма шунда ук
нигә ачуланганын оныта.
Шуннан чигелдәк белән чәй капчыклары
китерә дә, һава торышы
турында аңлата.

Әни бик арыган, стресс кичерә.
Әти эштә йокыга китә.
Беркөнне әби Филипкә,
әни мине үтерергә тырыша, дип аңлата.
– Әниең мине зәһәрләргә тели, – әйтә.
– Ул пешергән ризыкны ашамыйм инде.

Күсе зәһәре кушкан.
Тәмен сизәм.
– Ул синең даруың ачы, – Филип әйтә.
– Юк, ул зәһәр.
Дару тәмен беләм, –
үзсүзләнеп җавап бирә.
Икенче көнне әби ашамый, баш тарта.
– Мин Филип пешергәнне
генә ашыйм, – әйтә.
– Филип миңа аш пешерсен.
Ул гына миңа яхшы.
Башкалары һәммәсе
үлгәч акчамны гына телиләр.

Әни бик ачулана.
– Филипнең эше сиңа аш
пешерү түгел, – әни әйтә.
– Ник миңа ачуланасың?
Мин сиңа нәрсә эшләдем?
Әби җавап бирми.
Тәрәзәдән тышка карый.

Шул ук көнне кичен әти җитди
рәвештә әни белән Филипкә сөйли:
– Сиңа ялга китәргә кирәк, –
әнигә әйтә.
– Бу болай дәвам итсә,
без барыбыз да хасталанабыз.

Без әле әбине картлар йортына
урнаштырырга тиеш.

– Минем хәлемнән килми инде, –
әни төелеп әйтә.
– Көчем дә калмады.
Алай булса да аны картлар йортына
урнаштырырга ярамый.
Ул бит минем әнием.
Ә мин булмаганда аны кем карар?

– Без булдырабыз,
шулай бит Филип? – әти әйтә.
– Картлар йорты турында уйла.
Мин үз фикеремне
үзгәрттем һәм әле мин Аяз
белән бер фикердә.

Филип башын ия,
ләкин бернәрсә дә әйтми.
Эчендә зур салкын кисәк.



# Бүлем 10

Әни ял итәргә китә.
Әнинең сәламәтлеге
җимерелергә тора дип табиб әйтә.
Һәр иртә һәм һәр кич Филип
әтисе белән әбигә бара.
Ашны әти пешерә дә,
Филип пешергән кебек кыланалар.
Шулай гына әби ашый.

Иртә белән Филип авыр тора.
Ул уяткыч сәгатьнең
шалтыравын ишетмәгәч,
мәктәпкә барырга соңга кала.
Аннары Филип мәктәпкә сөйрәлеп
барып җитә дә,
өстәле артында йокыга китә.

Хәлил аны гадәттә уята.
Филипнең дәресләрне утырып
тыңларга көче юк.
Сабакларын укымый.
Кулларын йөзенә куеп,
әби турында уйлап утыра.

Элек алар төрле нәрсәләр эшлиләр иде.

Әби Филипне музейларга
һәм галереяларга алып бара иде.
Алар бергә рәсемнәр һәм
һәйкәлләр карыйлар иде. Филипне
чигелдәк пешерергә өйрәткән иде.
Элек барысы да күңелле иде.

Әлеге заманда әбине уйлау йөрәккә тия.
– Әүвәлге әбием кая китте? –
Филип зарлана.
– Бу минем әбием түгел.
Бу ят кеше.
Тышкы күренеше дә үзгәрә бара.
Тәне кибә һәм көннән-көн
кечерәя бара кебек.

– Яхшы вакытларны хәтерлә, –
Хәлил әйтә.
– Ул һаман да синең әбиең бит.
Ул, үзе теләмәсә дә, үзгәргән.
Бөтен дөнья үзгәргән кебек үк,
вакыт узу белән кешенең тәне дә үзгәрә.

– Мин аның шул ук кеше булып калуын
телим, – Филип әйтә.
– Нигә аңа үзгәрергә кирәк?
– Без дә үзгәрәбез бит, –
Хәлил җавап бирә.

– Тәндә һәртөрле мөмкин
булган процесслар бар.
Миңа калса, беркем дә гомере буе
бер үк кеше булып кала алмый.

– Әлеге заманда әби бик ачулы, –
Филип әйтә.
– Әти аны актив булырга өнди.
– Хәрәкәт ул баш миен эшләтеп тора, –
әти әйтә.
– Ләкин әби паникага керә яки
бөтенләй сәбәпсез ачулана, – Филип өсти.
– Эшең җиңел түгел, – Хәлил әйтә.

Филип уйлап кала.
Мәктәптә укытучылар карар кылалар.
Дикъкатьле булырга кушалар.
Сабакларыңны укы.
Спортта катнаш.
Тыңла.
Өйдә әти карар кыла һәм
әби әмерләр бирә.
Бөтен вакыт Филипкә
ни булса эшләргә кирәк.

Әни көн саен шалтырата.
– Әби турында аңлатма, –
әти кисәтә.

– Ул борчыла гына.
– Сиңа укытучыларга сөйләргә кирәк, –
Хәлил әйтә.
– Сиңа авыр булганны аңлыйлар бит.
– Мин алай уйламыйм, – Филип әйтә.
– Алар миңа кычкыралар гына.

Бу вакытларда Филип һәрнәрсәгә
һәм һәркемгә ачулана.
Хәлил иңбашын сикертә.
– Чик куй, – дия.
– Нигә әбине кемгә булса
башкага карарга бирмисез?

– Берни дә аңламыйсың, –
Филип төелеп әйтә.
Ләкин дөрес уйламаганын эченнән белә.
Ул чикләр куймый.
Ул хәленнән килмәгәнне
эшләргә тырыша гына.
– Күпме дәвам итәр бу? – Филип уйлый.
– Күпме әтиеңнең хәленнән килер? –
Хәлил сорый.
– Синең көчен күпмегә җитәр?

– Әбием турында бит сүз бара, –
Филип әйтә.
– Без аны читкә калдыра алмыйбыз.

‒ Калдырмыйсыз бит,
әгәр дә дөрес карар кылсагыз, ‒
Хәлил әйтә.

‒ Дөрес карар нинди? ‒
Филип сорый.
Хәлил башын чайкый да:
‒ Аны әйтә алмыйм, әмма
сез карар кылырга тиеш, ‒ әйтә.

Сәгать өчтә әти шалтырата.
‒ Әби янына бара аласыңмы? ‒
сорый.
Филип дәшми.
‒ Мин кирәкле бер җыелышта.

Әбигә барганда Филипнең
йөрәге таш кебек авыр.
Ул теләбрәк йоклар гына иде.
Әбинең өй ишеген ачып җибәрә.

Әби кухня идәнендә егылып ята.

# Бүлем 11

Филип калтыранып китә.
Тирән генә сулап ала да,
әби янына бара.
Бармаклары белән әбинең
муенын һәм колак төбен тотып карый.
Әбинең йөрәге тибә.
Хуштан киткән.

Филип әтисенә шалтырата,
ләкин әти җавап бирми.
Аннары Аяз абыена шалтырата.

Аяз абый ун минуттан соң килә.
Ул ашыгыч ярдәм чакырган.
Шунда амбуланс килеп тә җитә.
Әби идәндә яткан.

Филип аның өстенә япма салган.
Ул үзе урындыкка утырган да, калтырана.
– Әбине күчердеңме? – Аяз абый сорый.
– Юк, ул егылган җирендә, – Филип әйтә.

Амбуланс йөртүче һәм Аяз абый
сакланып кына әбине ташыгыч
өстенә күтәрәләр.

Алар аны амбуланска илтәләр.
Филип һәм Аяз абый ялгыз калалар.
Аяз абыйның якында булуы
Филипкә иминлек хисе бирә.

– Без авто белән хастаханәгә
китәбез, – Аяз әйтә.
Хәлең ничек?
Барысы да яхшымы?
Әйе дип Филип башын кага.
Аннары юк дип башын чайкый.

– Куркындың ахрысы, – Аяз абый әйтә.
– Әмма әби көчсезгә охшамый бит.
Нигә егылды икән, аптырап калдым.
Дөрес ашый микән?
– Без пешергәнне ашый, –
Филип мыгырдана.
– Шулай әйтә.
Ләкин кем булса аны үтерергә
тора дип тә әйтә.

Аяз абый суыткычны ачып карый.
Анда рәт-рәт савытлар һәм банкалар тора.
– Ой, Аяз абый кычкырып җибәрә.
– Бу ризык бер футбол төркеменә
җитәр иде!

– Ризыкны әти банкаларга тутыра, –
Филип әйтә.
– Шулай әби теләгән
вакытында ашый ала.
– Әмма ул ашамый, –
Аяз абый мыгырдый.
– Аңа витаминнар һәм минераллар,
әлбәттә, җитешми.
Бу аның хәлен тагын да начарайта.
Дару шкафы ничек икән?

Аяз бер кечкенә шкаф янына
барып аны ача.
– Даруларын да алмый икән, – әйтә.
– Хәле начар булырга тиеш.
Монда авыртулар һәм психик проблемалар
өчен дарулар бар.
Болардан ул хастарак кына була.

– Әбинең авыруына каршы дару
табыламы? – Филип сорый.
– Юк, мин һәрхәлдә белмим, – Аяз әйтә.
– Әмма хәле яхшырак булсын өчен
без күп эшли алабыз.
Аны музейларга һәм күргәзмәләргә
алып барырга кирәк.
Аннары ул элеккеге кебегрәк
булырга мөмкин.

Тирә-ягында кешеләрнең булуы
да кирәкле.
Бәлки дә ара-тирә массаж
һәм дикъкатьле карау.
Музыка, бию һәм тышта йөрү.
Яхшы кешеләр һәм
күңелле сөйләшүләр.
Иң мөһиме – дөрес ашарга кирәк.

Аяз абый һәм Филип хастаханәгә керәләр.
Әби зур ятакта ята.
Уянган, бик сөйләшә алмый.
Филип аны кулыннан тота,
әби чыраен сыта.
– Авырттыра, авырттыра, – дия.
– Кайчан булса хәле яхшырак булырмы? –
Филип гаҗәпләнә.

– Яхшырак була ала.
Ләкин беркайчан да
бөтенләй сәламәтләнми, –
Аяз җавап бирә.
– Бик яман чир инде, –
Филип мыгырдана.
– Филип, иң мөһиме әле без аны мөмкин
кадәр яхшы карыйк, – Аяз әйтә.
– Безгә чынбарлыкны
кабул итәргә кирәк.

Деменцияне ничек туктатырга,
аны әлегә беркем белми.

– Мин үләргә телим, – әби мыгырдана.
Филип эчендәге салкынлыкның
тамакка күтәрелүен сизә.
– Әби, сиңа үләргә
ярамый, – Филип кычкырып җибәрә.
– Сиңа сәламәтләнергә кирәк,
ишетәсеңме?



# Бүлем 12

Икенче көнне Филип белән Хәлил
мәктәп бакчасында
эскәмиядә утыралар.

– Иртәгә әбине хастаханәдән
картлар йортына күчерәләр, –
Филип аңлата.
– Аяз абый моны җайлаган.
Әбине әле көпшә аша ашаталар.
Ләкин тиздән ул
гадәттәгечә ашый алачак.

– Әниең ни әйтә? –
Хәлил сорый.
– Башта теләмәде, –
Филип аңлата.
– Бибинур апа истерикага бирелде.
Җиде тапкыр шалтыратты һәм дә
әтигә акырды-бакырды.
Аннары кузиным София аның
телефонын яшерде.
Ул безнең карар белән килешә.

– Син ни уйлыйсың? – Хәлил сорый.
– Картлар йорты әби өчен иң яхшысы.

Әни дә моны аңлый, әмма апага күбрәк
вакыт кирәк, – Филип әйтә.
– Ә абыең?
Ул ни әйтә? –
Хәлил гаҗәпләнә.
– Абый шат, – Филип җавап бирә.
– Әле әбине яхшы карыйлар.
Абыйга әнине юатырга да,
Бибинур апаны
тынычландырырга да кирәк.

– Шелтәләр белән ни эшлисең?
Сабакларыңны укымаганың
өчен берне алдың бит.
Аннары икенчесен математика
дәресендә йокыга
киткәнең өчен, – Хәлил әйтә.
– Аларны әниеңә күрсәттеңме?
– Юк, – ди Филип,
йөзе кызарып китә.

– Филип, болар оят түгел бит.
Башкаларның да әбиләре яки бабайлары
деменция белән авырый, –
Хәлил әйтә.
– Бу байтак еш проблема.
Син нигә укытучыларга һәм ректорга
әбиең турында аңлатмыйсың?

– Хм, – Филип әйтә.
– Бәлки дә.

– Синең гаебең юк нәрсәдән
оялма инде, – Хәлил әйтә.

– Син беләсеңме, ник берәүләргә
деменция була икән, –
Филип гаҗәпләнә.
– Картайганда тәннең химиясе үзгәрә, –
Хәлил җавап бирә.

– Син һаман да шул химия турында
уйлыйсың, – Филип елмая.
– Мускуллар, сөякләр һәм
кан тамырлары кебек нәрсәләр
турында да шулаймы?

– Әлбәттә, – Хәлил җавап бирә.
– Ләкин кеше сәламәт яшәсә,
деменциядән алдан саклана ала.
– Беркем дә тулы ышанычлык бирә
алмый, – Филип әйтә.
– Әби беркайчан да элекке
кебек булмый дип абый әйтә.
Ничек алай була ала?
Ничек кеше бөтенләй үзгәрә ала,
шуны әйтергә телим?

– Баш мие, – Хәлил әйтә.
– Баш мие үзгәрә.
Ничек һәм нигә,
аны беркем дә белми.
Тәмам җир шары кебек.
Климат нигә үзгәрә,
теорияләр бик күп.
Ләкин әлегә без бу
турыда бик аз беләбез.

Филип белән Хәлил бер
мизгел әкрен торалар.
– Беләсеңме, мин ни уйлыйм? –
Филип сорый.
– Деменция эчтәге томан кебек.
Томан төшкәч, бөтен дөнья юкка чыга.
– Ни әйтергә телисең? –
Хәлилнең исе китә.

– Бер нәрсә дә күреп булмый,
башкалар кайда икәнне
белеп булмый.
Кайвакыт томан ачыла да,
кемне булса да күреп була.
Аннары томан тагын төшә, –
Филип аңлата.
– Шунда тирә-яктагы дөнья
белән элемтә югала.

Хәлил уйлый.
– Бу акыллы фикер, – әйтә.
– Миңа калса, томан эчкә төшкәндә,
кеше үзен бик ялгыз
һәм күңелсез хис итә.
Һәм дә җиңел саташа.

Филип әкрен утырып тора.
Ахырда әйтә:

– Иртәгә минем белән әби янына
картлар йортына
барырга телисеңме?
Бәлки без аңа томан
эчендә дөрес юлны табарга
ярдәм итә алырбыз.
Аның яраткан музеена барсак.
Ни уйлыйсың?



**Филипнең әбисе элекке**
**кебек түгел.**
**Ул өйдән качкалый,**
**акчасын урлыйлар дип шикләнә.**

**Филипнең гаиләсенә әби турында**
**мөһим карар чыгарырга кирәк.**
**Фикерләре хыяллар гынамы?**

**Әбине карауны ничек башкарырга,**
**аларга уйларга кирәк?**

**Беркөнне Филип әбисен**
**идәндә егылып яткан килеш таба.**

2 җиңел тел

978-952-7334-83-6

ISBN 978-952-7334-83-6 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-84-3 (е-китап, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**